ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2016 елның 28 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгәннән соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмә Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә

капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен мондый урын милекчесенә карый торган күпфатирлы йорттагы урынның бер квадрат метр гомуми мәйданына бер айга 5 сум күләмендә билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Н. Юсипова — 1960 елда төзелгән күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе. 2014 елда әлеге йортка капиталь ремонт ясалган.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, дәгъва белдерелә торган норма, йортның төзелү елын, ничә катлы булуын, күпфатирлы йорт урнашкан муниципаль берәмлекне, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча эшләр исемлеген исәпкә алмыйча, бөтен күпфатирлы йортларга карата капиталь ремонт өчен кертемнең бертөрле минималь күләмен билгели, бу исә аның конституциячел хокукларын бозуга китерә.

Гражданка Г.Н. Юсипова ассызыклаганча, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе субъектларына капиталь ремонт өчен кертемнең дифференциацияләнгән минималь күләмен билгеләү хокукын биргән. Республика закон чыгаручысы үз чиратында күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырган. Ләкин Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, мөрәҗәгать итүче уйлавынча, күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең дифференциацияләнгән минималь күләмен билгеләү турындагы федераль һәм республика законнары таләпләрен исәпкә алмаган һәм андый кертемнең бердәм минималь күләмен билгеләгән.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 7 февралендәге 41/пр номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты тарафыннан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрнең 8.1 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектына

кертемнең минималь күләмен билгеләгәндә һәм кертемнең билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фондларындагы акчалар хисабына күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясауны финанслаганда кулланыла торган шушы ук пунктта саналган мәгълүматларны бастырып чыгарырга тәкъдим ителә. Шул ук вакытта күрсәтелгән Методик тәкъдимнәрнең 8.2 пункты нигезендә әлеге мәгълүматларны Россия Федерациясе субъектының капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгели торган норматив хокукый актына кушымтага (кушымталарга) кертергә тәкъдим ителә. Ләкин, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, дәгъва белдерелә торган нигезләмә белән капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме күрсәтелгән мәгълүматларны бастырып чыгармыйча билгеләнгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче өлеш), 49 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 8.1 пункты буенча капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәр нигезендә Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йорттагы урын милекчесе биләгән урынның гомуми мәйданыннан чыгып билгеләнә һәм күпфатирлы йорт урнашкан муниципаль берәмлеккә карап, йортның төрен һәм ничә катлы булуын, күпфатирлы йорттагы төзелеш конструкцияләренең аерым элементларына һәм инженерлык системаларына капиталь ремонт ясау хакын, чираттагы капиталь

ремонт ясаганчы алардан нәтиҗәле файдаланунының норматив срокларын (ремонтара норматив сроклар) исәпкә алып, шулай ук күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча әлеге Кодекста һәм Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актында билгеләнгән эшләр исемлеген исәпкә алып дифференциацияләнергә мөмкин.

Дәгъва белдерелә торган карарны кабул итү моментына Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының 2013 елның 10 июлендәге 288 номерлы боерыгы белән расланган Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр гамәлдә булган, алар хәзер үз көчен югалткан. Әлеге Методик тәкъдимнәрнең 1.3 пункты мәгънәсе буенча Россия Федерациясе субъектына күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләүне күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәтләрне һәм (яки) эшләрне финанслау өчен акчаларга гомуми ихтыяҗны билгеләү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә гомуми чыгымнарны исәпкә алып, гражданнарга — күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә кертемнең минималь күләме түләрлек булу, кертемнең билгеләнә торган минималь күләменнән чыгып булдырыла торган финанс чараларының җитәрлеге принциплары нигезендә башкарырга тәкъдим ителгән.

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләүнең тиңдәш принциплары хәзерге вакытта «Капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 июнендәге 454/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән.

Федераль законнарның китерелгән нигезләмәләрен, шулай ук «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нормаларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карар кабул ителгән. Дәгъвалана торган нормада каралган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләме беренче чиратта капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм эшләрнең билгеле исемлеген финанслау тиешлегенә, гражданнарга — күпфатирлы йортлардагы фатирлар милекчеләренә түләрлек булуына бәйле һәм үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонтны вакытында ясауны тәэмин итүгә юнәлгән.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 28 июлендәге 519 номерлы карары белән законнарда билгеләнгән тәртиптә басылып чыккан Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге расланган.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган җайга салуда аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Татарстан Республикасындагы күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен үзгәртү турында ул куйган сорауны хәл итү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота,

бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды гамәлдәге җайга салуда милекчеләрнең күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау белән бәйле чыгымнарны финанслау күләмен үзгәртү хокукларын гамәлгә ашыруларында чикләүләр булмавына игътибар итә, бу Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 8.2 өлешендә каралган, аның нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемне Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән билгеләнгән шундый кертемнең минималь күләменнән күбрәк күләмдә билгеләү турында карар кабул итә алалар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы

Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 25-О**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**